РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Чемодуровского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. Нагорная, д. 1А, Азнакаевский район,
с.Чемодурово, 423307,
тел./факс (885592)33-1-61
E-mail: Chmd.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Чемодурово авыл җирлеге
башкарма комитеты

Нагорная ур., 1 А йорт, Азнакай районы,
Чемодурово авылы, 423307
тел./факс (885592)33-1-61
E-mail: Chmd.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «3» май 2018 г.** **№ 7**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге башкарма комитетының 15.11.2017 №17 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге территориясендә планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл жирлеге башкарма комитетының 15.11.2017 №17 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге территориясен планлаштыру документларын әзерләү тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге территориясендә планлаштыру документларын әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2. 2.10 пунктында «Гавами тыңлаулар» сүзләрен «Ижтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

1.3 2.11 пунктында «Гавами тыңлаулар» сүзләрен «Ижтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.14. Иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре басылып чыккан көнгә кадәр аларны уздыру турында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге халкына хәбәр иткән көннән алып иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Уставы һәм (яисә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да ким өч айдан артыграк була алмый. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Н.Б.Котельникова